**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актанышав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тәкъдимнәре нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 14 июлендәге ПР-380 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2 өлешенең 2.4.пунктын бәян итеп, түбәндәге редакциядә үзгәрешләр кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Хезмәтләр күрсәтү вакыты, шул исәптән хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге РФ законнары белән каралган очракта хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Төзелешкә рөхсәт бирү - гариза биргән көнне дә кертеп, биш эш көненнән дә артык түгел.<br>Төзелешкә рөхсәт срогын озайту - биш көн.<br>Төзелешкә рөхсәт дубликатын бирү - өч көн. | РФ 51 грк. 11 ст. |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең экономика буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Н. Фәттахов